**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**Муслюмовский муниципальный район Республики Татарстан**

**Баланнинская ООШ**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | |
|---|---|---|
| ШМО учителей начальных классов | Заместитель директора по УВР Ахметова С.Ф. | ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ<br>СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП<br>Сертификат: 00A3F5BA0A9DE06A6D37E18410DFF14482<br>Владелец: Сафин Фатих Нуруллович<br>Действителен с 05.07.2023 до 27.09.2024 |
| Газымова Г.Р.<br>Протокол № 1 от «28» августа 2023 г. | Протокол № 1 от «29» августа 2023 г. | |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**учебного предмета «Родной (татарский) язык»**

для обучающихся 1– 4 классов

**Баланны 2023**



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 1 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**“Туган тел” (татар теле) укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре**

## УКЫТУНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЕЛЫ

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- телнең милли аңның нигезе булуы турында беренчел белемнәр формалаштыру;
- дөрес сөйләм һәм язма телгә уңай караш булдыру;
- татар теленең нормалары турында башлангыч белем күнекмәләре алу;
- сүзләрне дөрес, аңлап уку һәм язу;
- телнең төзелеше, системасы турында белемнәр булдыру; телнең төп берәмлекләрен, аларның билгеләрен, аермалы якларын өйрәнү;
- телнең төп берәмлекләрен, грамматик категорияләрен танырга һәм анализларга өйрәнү, тел берәмлекләрен дөрес итеп куллана белү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- алфавитта тамгаларның(хәрефләрнең) урнашу тәртибен белү ;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**

- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

## УКЫТУНЫҢ ИКЕНЧЕ ЕЛЫ

***Шәхси нәтиҗәләр***:

- туган илгә карата шәхси караш булдыру;
- чын кеше сыйфатлары булдыру;
- мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү;
- этик хисләр, мөлаемлылык үстерү;
- рухи-әхлакый идеалларына китерү.
- олылар белән хезмәттәшлек;



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 2 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33

- аралашу культурасы күнекмәләре .

***Метапредметлы нәтиҗәләр:***

- аң -белем  үстерү;
- проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу;
- эзләнү юлларын һәм нәтиҗәләрен ачыклау;
- логик фикерләү:чагыштыру,синтез, анализ ясый белү;
- конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу;
- укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү;

***Предметлы  нәтиҗәләр:***

- Россиядә күп милләт  халыкларының төшенчәсен бирү;
- татар теленең төп  төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик);
- татарча югары сөйләм культурасы формалаштыру;
- туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре;
- сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру;
- уку, язу гамәлләре формалаштыру;
- сүзгә фонетик анализ ясый белү.

***<u>Шәхескә юнәлтелгән  УУГ (универсаль уку гамәлләре)-ШУУГ</u>***

- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасын күрсәтү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;
- дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;
- үз уңышларың-уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү;
- кече яшьтәге мәктәп баласы үзе  тел берәмлекләрен танып, таныш һәм таныш булмаганнарга бүлә белү;
- биремнәр системасында ориентлашырга  өйрәнү.

***<u>Танып белү  универсаль уку гамәлләре ТБУУГ</u>***

- үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм  информацияне бәяли белү;
- логик фикерләү чылбырын төзү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;
- мәгълүмат җиткерүче символларны уку;
- тормыш тәҗрибәсен кулланып, ситуациянең моделе буенча текст төзү;
- тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;
- материаль объектлар (фишкалар) кулланып биремнәр үтәү;
- анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару

***<u>Регулятив (көйләгеч)  универсаль уку гамәлләре-РУУГ</u>***

-көч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү;
-белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
-үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
-эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
-үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
-бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;

-дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
-тормыш тәҗрибәсен куллану;
-үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;
-укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү.

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре -КУУГ***

- тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- күзаллау, фаразлау; логик фикер йөртү осталыгы; күршең белән хезмәттәшлек итү; фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру; үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;
- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү; иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү.

## УКЫТУНЫҢ ӨЧЕНЧЕ ЕЛЫ

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- туган илгә карата шәхси караш булдыру;
- чын кеше сыйфатлары булдыру;
- мөстәкыйльлелек һәм җаваплылык үстерү;
- этик хисләр, мөлаемлылык үстерү;
- рухи-әхлакый идеалларына китерү.
- олылар белән хезмәттәшлек;
- аралашу культурасы күнекмәләре .

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

- аң -белем үстерү;
- проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу;
- эзләнү юлларын һәм нәтиҗәләрен ачыклау;
- логик фикерләү:чагыштыру, синтез, анализ ясый белү;
- конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу;
- укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү;

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- Россиядә күп милләт халыкларының төшенчәсен бирү;
- татар теленең төп төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик);
- татарча югары сөйләм культурасы формалаштыру;
- туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре;
- сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру;
- уку, язу гамәлләре формалаштыру;
- сүзгә фонетик анализ ясый белү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

***Танып белү универсаль уку гамәлләре:***

- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.
***Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:***
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

## УКЫТУНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ ЕЛЫ

Программа белән эшләүнең төп максаты – 4 нче сыйныф ахырына планлаштырылган (яки көтелгән) нәтиҗәләргә ирешү. Алар түбәндәгеләр:
– **шәхси нәтиҗәләр**: укучының өйрәнгән предметы (татар теле) буенча алган белем һәм күнекмәләре аның шәхес булып формалашуы өчен нигез була ала; уку һәм танып белүгә битараф булмау, тормышка актив караш тәрбияләнә. Бу нәтиҗәләр баланың рухи-әхлакый үсешенә, сәламәт һәм хәвеф-хәтәрсез яши белүенә дә бәйле;
– төрле предметларны өйрәнү белән бәйле **предметара яки универсаль нәтиҗәләр** танып белү һәм аралашу өлкәсенә карый. Татар теле дәресләрендә укучыларның рус теленнән алган белем һәм күнекмәләре дә ярдәмгә килә. Мондый нәтиҗәләр телнең төрле бүлекләрен үткәндә дә, аралашканда да күренә;
– **аерым предметны** (татар телен) өйрәнү нәтиҗәләре шушы өлкәгә караган белемгә ия булуны, аны үзгәртеп (яки үзгәртмичә) гамәлдә куллана белүне күз уңында тота.
Башлангыч мәктәптә татар телен өйрәнүгә нигез салына. Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычында укучылар телне аралашу чарасы һәм милли мәдәниятнең чагылышы буларак аңларга өйрәнәләр, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлегенә төшенәләр. Татар теле укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү өчен нигез булып тора. Татар телен өйрәнү вакытында укучылар телдән һәм язма аралашу мөмкинлегенә ия булалар һәм телне, уку биремнәрен үтәү максатыннан чыгып, кирәкле мәгълүматны төрле чыганаклардан эзләп табу өчен кулланырга өйрәнәләр.
Россиядә тел һәм мәдәният киңлегенең бердәмлеге һәм күптөрлелеге, телнең милли үзаң формалаштыру нигезе булуы турында беренчел күзаллау булдыру.
Укучыларның телне милли мәдәният күренеше һәм аралашуның төп чарасы дип, татар телен милләтара аралашу теле итеп танулары.
Кешенең гомуми культура күрсәткече, гражданлык позициясе булган телдән һәм язма дөрес сөйләмгә карата уңай караш формалаштыру.
Татар әдәби теле нормалары (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуация), сөйләм әдәбе кагыйдәләре турында беренчел күзаллауга ия булу.
Аралашу вакытында куелган максат, бурыч һәм чаралардан чыгып, өйрәнгән материалны куллана белү; катлаулы булмаган монологик сөйләм һәм язма текстлар төзегәндә, коммуникатив бурычларны уңышлы үтәү өчен, туры килгән тел чараларын сайлый белү күнекмәләрен формалаштыру.
Хатасыз язуны культура дәрәҗәсенең бер күрсәткече итеп тану; үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстларны язганда, орфография һәм тыныш билгеләре кагыйдәләрен дөрес куллана белү.
Танып белү, гамәли һәм коммуникатив биремнәрне чишү өчен тел берәмлекләре һәм уку гамәлләренә ия булу;
Татар теленең системасы һәм төзелеше: фонетика, графика, лексикология, сүз төзелеше һәм сүз ясалышы, морфология һәм синтаксис; төп тел белеме берәмлекләре һәм аларның үзлекләре, сөйләмдә куллану үзенчәлекләре турында беренчел фәнни караш булдыру.

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларда белем алу осталыгы нигезе буларак **танып белү, коммуникатив, регулятив һәм шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре формалашачак.**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:


Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 5 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33

• мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
• күнегүләрне мөстәкыйль эшләү алымнарын үзләштерергә;
• тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;
• материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;
• бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;
• фикерләүдә логик чылбыр төзергә;
• уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*• интернетны кулланып, мәгълүмат эзләргә;*
*• мөстәкыйль рәвештә нигезләмә һәм критерийлар сайлап, чагыштыру, сериация һәм классификация башкарырга;*
*• сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыруны үз эченә алган логик хикәяләү тө-зергә.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:
• партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;
• нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;
• килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;
• сораулар формалаштырырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*• сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алырга;*
*• монолог төзергә.*

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:
• таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерегә;
• гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
• кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;
• максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;
• сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*• партадаш күршең белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләрен куярга;*
*• уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен, мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә;*
*• ирешеләчәк нәтиҗәне алдан фаразларга;*
*• яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкәнче үз мөмкинлекләреңне мөстәкыйль бәяләргә.*

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре**

Укучыларда формалашачак:
• татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
• дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
• үз уңышларың/уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
• нормалардан тайпылышны күрү;

## ЭШ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

### УКЫТУНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЕЛЫ

Программа **атнага 3 сәгать исәбеннән 99 сәгатькә төзелде.**

**Тематик планлаштыру**

| № | Дәрес темасы | Сәг саны |
|---|---|---|
| | | |
| 1 | Нокталар төртү,авыш сызыклар. Озын һәм ыргаклы туры сызыклар | 1 |
| 2 | Озын туры сызык,астан элмәкле туры сызыклар, аларны тоташтыру | 1 |
| 3 | Ике элементны тоташтыру һәм кечкенә озынча овал, ике башы ыргаклы таяк. | 1 |
| 4 | Юл а хәрефе. Баш А хәрефе<br>Юл ә хәрефе. Баш Ә хәрефе | 1 |
| 5 | Юл ы хәрефе. Баш Ы хәрефе. | 1 |
| 6 | Юл э хәрефе. Баш Э хәрефе | 1 |
| 7 | Юл и хәрефе. Баш И хәрефе. | 1 |
| 8 | Юл у хәрефе. Баш У хәрефе. | 1 |
| 9 | Үү хәрефләре | 1 |
| 10 | Оо хәрефләре | 1 |
| 11 | Өө хәрефләре | 1 |
| 12-13 | Юл н хәрефе. Баш Н хәрефе | 2 |
| 14-15 | Л.л хәрефләре | 2 |
| 16-17 | Мм хәрефләре | 2 |
| 18-19 | Юл р хәрефе. Баш Р хәрефе | 2 |
| 20 21 | Й,й хәрефләре | 2 |
| 22 | ң хәрефе | 1 |
| 23- 24 | Юл я хәрефе. Баш Я хәрефе | 2 |
| 25 26 | Юл ю хәрефе. Баш Ю хәрефе. | 2 |
| 27 28 | Юл е хәрефе. Баш Е хәрефе. | 2 |
| 2930 | Юл д хәрефе. Баш Д хәрефе. | 2 |
| 31 -32 | Юл т хәрефе. Баш Т хәрефе. | 2 |
| 33 -34 | Юл з хәрефе. Баш З хәрефе. | 2 |
| 35 | Юл һәм баш С,с хәрефләре. | 1 |
| 36 -37 | Юл г хәрефе. Баш Г хәрефе. | 2 |
| 38 | Юл к хәрефе. Баш К хәрефе. | 1 |
| 37 | Юл в хәрефе. Баш В хәрефе. | 1 |
| 40- 41 | Юл ф хәрефе. Баш Ф хәрефе. | 1 |
| 42 | Юл б хәрефе. Баш Б хәрефе. | 1 |
| 43 44 | Юл п хәрефе. Баш П хәрефе. | 2 |
| 45 | Юл ж хәрефе. Баш Ж хәрефе. | 1 |
| 46 47 | Юл ш хәрефе. Баш Ш хәрефе. | 1 |
| 47 | Җ,җ хәрефләре. | 1 |
| 49 | Ч, ч хәрефләре. | 1 |
| 50 | Сүзлек диктанты | 1 |
| 51 | Х, х хәрефләре. | 1 |



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 7 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| 52 -53 | Һ, һ хәрефләре. | 2 |
| 54 55 | Ё,ё | 1 |
| 56 | Щ, щ хәрефләрен. | 1 |
| 57 58 | Ц, ц хәрефләре. | 1 |
| 59 | Ь һәм Ъ хәрефләре | 1 |
| 60 | Алфавит. | 1 |
| **Сүз һәм җөмлә 6 сәг** | | |
| 61 | Әминә белән Әмир алфавит өйрәнә | 1 |
| 62 | Алфавит турындагы белемнәрне ныгыту. | 1 |
| 63 | Җөмлә . | 1 |
| 64. | Җөмлә ахырында ты-ныш билгеләре. | 1 |
| 65. | Предметны белдергән сүзләр. Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. | 1 |
| 66. | Предметның билгесен белдергән сүзләр. | 1 |
| 67. | Өстәмә предметны белдергән сүзләр. | 1 |
| 68. | Ярдәмче сүзләр. | 1 |
| **Сөйләм** | | |
| 69. | Телдән һәм язма сөйләм. | 1 |
| 70 | Телдән һәм язма сөйләм.Басым. | 1 |
| 71. | Исем, фамилия, елга, күл, шәһәр, хайван кушаматларында баш хәреф.. | 1 |
| 72 | Хайван кушаматларының язылышы. | 1 |
| 73. | Шәһәр, авыл һәм елга атамалары. | 1 |
| **Авазлар һәм хәрефләр** | | |
| 74. | Сузык авазлар. | 1 |
| 75 | Калын һәм нечкә сузыклар. | 1 |
| 76 | Иҗек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. | 1 |
| 77. | Тартык авазлар. | 1 |
| 78. | Парлы һәм парсыз тартык авазлар. | 1 |
| 79. | Э – е хәрефләре. | 1 |
| 80 | Ө – е хәрефләре. | 1 |
| 81. | О – ы хәрефләре. | 1 |
| 82. | **Я** хәрефе. | 1 |
| 83. | Тикшерү эше. Күчереп язу | 1 |
| 84. | **Ю** хәрефе. | 1 |
| 85. | **Е, е** хәрефләре. | 1 |
| 86 | Й хәрефе. | 1 |
| 87. | В хәрефе. | 1 |
| 88 | К,г хәрефләре. | 1 |
| 89. | М, н, ң хәрефләре. | 1 |



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 8 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| 90 | “Сузык авазлар “темасын ныгыту | 1 |
| 91. | “Тартык авазлар” темасын ныгыту. | 1 |
| 92. | Баш хәрефтән язылa торган сүзләрне ныгыту | 1 |
| 93. | Я,ю.е хәрефләренең язылышын кабатлау, ныгыту. | 1 |
| 94. | Сүзләрне юлдан юлга күчерү, иҗеккә бүлү-не кабатлау . | 1 |
| 95. | “Җөмлә”темасын ныгыту | 1 |
| 96 | Контроль күчереп язу | 1 |
| 97-99 | Барлык өйрәнгәннәрне кабатлау. | 3 |

**Программаның курсының эчтәлеге**

**Язарга өйрәнү. Әзерлек чоры – 4 сәгать**

Язганда дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре белән танышу. Дәфтәр битләрендә ориентлашу, андагы сызыклар белән танышу. Вертикаль, горизонталь һәм авыш сызыклар турында белешмә.

Татар алфавиты хәрефләре график системасының структур берәмлеге буларак кулланылган элемент-сызыклар. Алгоритм буенча элемент-сызыкларны язу. Язма хәрефләрнең өлге формалары белән танышу. Бордюр-бизәкләр ясау процессында язма хәреф элементлары турында күзаллау тудыру.

График системаның структур берәмлеге булган язма хәреф элементларын чагыштыру, төркемләү һәм йомгаклау, гомуми нәтиҗә ясауга корылган логик күнегүләр үтәү.

**Әлифба чоры – 56 сәгать**

Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре. Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.

Уку дәресләрендә элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру.

Язу дәресләрендә элемент-өлгеләрдән язма хәрефләр төзү һәм анализлау. Гомуми уртак элемент формалары буенча хәрефләрне төркемләү һәм чагыштыру буенча логик биремнәр үтәү.

Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү.

Язуда оч төрле (өске, урта-йөзмә, аскы) тоташтыру алымы белән танышу.Дәрестә өйрәнелә торган хәрефне элек өйрәнелгән хәрефләр белән тоташтыру алгоритмнарын үзләштерү.

Тактлап язу алымы нигезендә кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшарту (киметү) белән ритмик чиратлаштыру күнегүләре.

Сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртү һәм алга таба язма хәрефләр белән язу. Язма хәрефләр белән бирелгән иҗек, сүз, җөмлә үрнәкләрен уку. үрнәк буенча язу. укучыларның үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерүләре.

**Әлифбадан соңгы чор – 33 сәгать**

Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту. Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу, әйтеп яздыра торган текстны язу.

**Татар теле**

**1. Сүз һәм җөмлә**

Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Җөмлә.. Җөмлә төзү. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. Өстәмә предметны белдергән сүзләр

Ярдәмче сүзләр.

**2. Фонетика һәм орфоэпия**

Сузык һәм тартык авазларны аера белү.Калын һәм сузык авазлар. Иҗек.

Тартык аваз хәрефләре. Парлы һәм парсыз тартыклар. Э-е, Ө-е, О-ы хәрефләре.

Я, ю,е хәрефләре.



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 9 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Тартык аваз хәрефләре. В хәрефе. К, г хәрефләре. Й хәрефе.
М, н, ң хәрефләре. Й хәрефе. Й хәрефе.

**3. Графика**

Алфавит. Алфавитны өйрәнү . Беренче хәрефенә карап, сүзләрне алфавит тәртибендә язу.

**4. Лексика**

Телдән һәм язма сөйләм. Басым.
Баш хәреф белән башлап языла торган сүзләр. Кеше исемнәре фамилияләре, хайван кушаматлары
Елга, күл исемнәрендә баш хәрефләр. Шәһәр, авыл исемнәрендә баш хәрефләр. Предметны атаган сүзләр
Предметларның эшен, хәрәкәтен атаган сүзләр.
Предметларның билгеләрен атаган сүзләр

## УКЫТУНЫҢ ИКЕНЧЕ ЕЛЫ

Атнага 3 сәгать исәбеннән барысы 102 сәгатькә төзелә.

**Фонетика һәм орфоэпия**

Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Язуда сузык авазларны белдерә торган хәрефләр. Аваз һәм хәрефләрне аеру. Сузык авазлар.

Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре.

Яңгырау һәм саңгырау, парлы һәм парсыз тартыклар. Язуда тартык авазларны белдерә торган хәрефләр. Татар теленә генә хас булган [w], [гъ], [къ], [х], [ч]; [ж], [ң], [h] авазлары.

*Е, ю, я* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу. Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы. Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе.

*ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу һәм уку.

**Графика**

Татар алфавиты: хәрефләрнең тәртибен һәм исемен яттан белү. Сүзлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.

**Сүз.** Сүз тамыры. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар. Сүз ясалу үзенчәлекләре.

Предметны белдергән сүзләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл, елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.

Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр. Аларның мәгънәсе һәм җөмләдә куллану үзенчәлекләре.

Предметның билгесен белдергән сүзләр, аларны җөмләдә куллану. Татар телендә исем һәм сыйфатның синтаксик бәйләнеш үзенчәлеге.

Сүз, сүзтезмә һәм җөмлә. Сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җыйнак һәм җәенке җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләдә сүз тәртибе. Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрләре, аларның дөрес әйтелеше.

**Бәйләнешле сөйләм.** Текстта җөмләләрнең урнашу тәртибе (үзара бәйләнеше). Текстның темасын билгеләү, төп фикерен табу. Текстны кисәкләргә бүлү һәм исем кую.

Рәсемнәр буенча, терәк сүзләр кулланып, текст төзү. Тәкъдим ителгән бирем буенча текстның эчтәлеген сөйләү.

Шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлау. Татар сөйләм әдәбенә хас булган сүзләрне дөрес куллану.

Башлангыч сыйныфларда ана телен өйрәнү –балаларга тел белеме буенча системалы мәгълүматләр бирү һәм сөйләм үсешен тәэмин итүдә беренчел этап.Бу чорда ана телен өйрәнү башка фәннәр белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.Татар теле дәресләрендә телнең системасы тирәнтен өйрәнелә,сөйләм культурасы үзләштерелә. Кече яшьтәге балаларның аралашу гамәлендә актуаль булган ситуацияләрдә кирәкле осталык һәм күнекмәләр булдырыла, сөйләм җанрының төрләре (записка,хат,котлау, чакыру язу) үзләштерелә.Орфография һәм пунктуацион кагыйдәләре фонетика,морфология, морфемика һәм синтаксисны өйрәнү кысаларында үзләштерелә.Ана теленең орфография принциплары белән танышу да кертелә.

Дәреслекне төзүче авторлар (ИМияссарова, К.Фәйзрахманова) тәкъдим итә торган УМК (программа , ике кисәктән торган дәреслек, методик кулланма, мөстәкыйль эш дәфтәре), ана телен укытуның традицион формаларын читкә какмыйча, укучыларда тел берәмлекләренә, заман таләпләреннән чыгып, уңай мөнәсәбәт тәрбияләүгә


Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 10 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

юнәлтелә.Дәреслекне төзүче авторлар 2 сыйныф укучысының яшь үзенчәлегенә нигезләнеп эшләгәннәр.Дәреслекләрдә “яшәүче” геройлар Әминә белән Әмир укучыларга программа материалын үзләштерергә ярдәм итәләр. Татар теле дәресләрендә укучыларның сүз байлыгын арттыру, даими рәвештә орфоэпик һәм орфографик нормаларны төгәл үтәү максатыннан,”Дөрес әйт””Дөрес яз” сүзлекләре һәм “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләүгә нык игътибар ителә.Дәреслекнең беренче кисәгендә укучылар яңа сүзләр белән танышалар,ә икенчесендә әлеге сүзләр белән сүзлекләр ярдәмендә эшләп, аларның дөрес әйтелеше һәм язылышы ныгытыла.”Аңлатмалы сүзлек”тән яңа өйрәнгән сүзнең мәгънәсен ачыклыйлар.Шул сүзләр белән сүзтезмә һәм җөмләләр төзетү, аларны диалог һәм монологлар төзүдә файдалану укучыларның сүз байлыгын арттырачак, бәйләнешле сөйләм оештырырга ярдәм итәчәк.Сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру төрле язма эшләр үтәгән вакытта да алып барыла.Сүзлек, искәртмәле, сайланма,күрмә, хәтер, иҗади,иркле,аңлатмалы диктантлар,зур булмаган текстны күчереп язу кебек эшләрдә дә андый күнекмәләр булдырырга ярдәм итә.(Диктант өчен үрнәк текстлар дәрес планында бирелә.Текстлар (язма эшләр) укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, телне белү дәрәҗәсен истә тотып сайлана)

**Авазлар һәм хәрефләр. Алфавит- 41 сәг**

-сузык һәм тартык авазларны аеру;
- нечкә һәм калын тартык авазларны аеру
-парлы һәм парсыз тартык авазларны билгеләү
-сүзләрне иҗекләргә бүлү
-сүзгә фонетик анализ элементлары
-аваз һәм хәрефне аеру.
-язуда ь һәм ъ хәрефләрен куллану
-е-ё. ю, я хәрефләре булган сүзләрдә аваз һәм хәреф бәйләнешен билгеләү
-алфавиттагы хәрефләрнең исемен дөрес әйтү, аларның урнашу тәртибен белү, алфавиттан файдалана белү.
-сүзлекләр яки белешмәлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү.

**Сүз , сүзнең атау функциясе – 39 сәг**

-сүзнең яңгыраш һәм мәгънә берәмлеге булуыгн аңлау
-бер һәм күп мәгънәле сүзләрне табу
-синоним
-сүзләрдә тамыр һәм кушымчаны аерып күрсәтү
-сүз төзелешен тикшерү
- тамырдаш сүзләр турында төшенчә булдыру
-сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү

**Җөмлә - 7 сәг**

-исем (предметны белдергән сүзләр), аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланышы
-ялгызлык исемнәрне таба белү
-исемнәрнең сан формалары
-сыйфат(предметның билгесен белдергән сүзләр), аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы
-сыйфатның (предметның билгесен белдергән сүзләр) сораулары
-сыйфатның (предметның билгесен белдергән сүзләр) исемгә бәйләнеп килүе
-фигыльнең (предметның эшен-хәрәкәтен белдергән сүзләр) мәгънәсе һәм сөйләммдә кулланылышы
-кисәкчәләр, аларның дөрес язылышы

**Бәйләнешле сөйләм- 15 дәрес**

-әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү
-уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү
-текст, текстның билгеләре
-тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге

-текст кисәкләренең эзлеклелеге
-кызыл юл турында төшенчә
-текстның планын төзү
-бирелгән план буенча үз текстыңны төзү
-изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу.

**Тематик планлаштыру**

| № | Бүлекләрнең һәм темаларның имсемнәре | Сәгать саны | Язма эшләр | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сүзлек диктанты | Изложение һәм сочинениеләр | Контроль диктант |
| 1 | Авазлар һәм хәрефләр | 41 | 4 | 3 | 5 |
| 2. | Сүз | 10 | | 1 | 1 |
| 3. | Сүзләрнең мәгънәләре | 29 | | 5 | 1 |
| 4. | Җөмлә | 7 | | 1 | 1 |
| 5. | Сөйләм һәм текст | 8 | | 1 | 1 |
| 6. | Кабатлау | 7 | | | 1 |
| | Барысы | 102 | 4 | 11 | 10 |

| № | Дәреснең темасы | Сәгать саны |
|---|---|---|
| **Авазлар һәм хәрефләр 41 сәг** | | |
| 1. | Тылсымчы китапханәсенә рәхим ите-гез.”Дөрес әйт” һәм “Дөрес яз” сүзлеге | 1 |
| 2. | Авазлар һәм хәрефләр | 1 |
| 3. | Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар. | 1 |
| 4. | О, ы хәрефләре. | 1 |
| 5. | О, ы хәрефләре. | 1 |
| 6. | Ө, е хәрефләре. | 1 |
| 7. | Ө, е хәрефләре. | 1 |
| 8. | Э, е хәрефләре | 1 |
| 9. | Кереш контроль диктант. **«Беренче сыйныфта үткәннәрне кабатлау”** | 1 |



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 12 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Хаталар өстендә эш. Э, е хәрефләре | 1 |
| 11. | Ижек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. | 1 |
| 12. | Тартык авазлар. | 1 |
| 13. | Тартык авазлар. *М,н, ң* хәрефләре. | 1 |
| 14 | В хәрефе. | 1 |
| 15. | В хәрефе.Сүзлек диктанты | 1 |
| 16 | К,г хәрефләре | 1 |
| 17. | К,г хәрефләре | 1 |
| 18. | К,г хәрефләре | 1 |
| 19. | Х. Һ хәрефләре | 1 |
| 20. | Х. Һ хәрефләре | 1 |
| 21. | Й хәрефе | 1 |
| 22. | Й хәрефе | 1 |
| 23. | Контроль диктант № 2 “**Авазлар һәм хәрефләр**” | 1 |
| 24. | Хаталар өстендә эш. Е, е хәрефләре | 1 |
| 25. | Е, е хәрефләре | 1 |
| 26. | Я хәрефе | 1 |
| 27. | Я хәрефе | 1 |
| 28. | Ю хәрефе | 1 |
| 29. | Ю хәрефе | 1 |
| 30. | Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы | 1 |
| 31. | Саңгырау тартыкларның яңгыраулашуы | 1 |
| 32. | Бертөрле ике тартык аваз хәрефләренең янәшә килүе. | 1 |



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 13 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| 33. | Ь хәрефе (нечкәлек һәм аеру билгесе | 1 |
| 34. | Ь хәрефе (нечкәлек һәм аеру билгесе | 1 |
| 35. | Ь хәрефе (нечкәлек һәм аеру билгесе | 1 |
| 36. | Ъ хәрефе (калынлык һәм аеру билгесе | 1 |
| 37. | **Контроль күчереп язу. “ъ һәм ь хәрефләре”** | 1 |
| 38. | Графика Алфавит | |
| 39-40 | Үткәннәрне кабатлау. **Тест. “Алфавит. Авазлар һәм хәрефләр”** | 2 |
| 41. | **Контроль диктант №4 “Алфавит. Авазлар һәм хәрефләр”** | 1 |
| **Сүз 19 сәг** | | |
| 42. -43. | Хаталар өстендә эш. Сүз. | 2 |
| 44. | Сүзнең тамыры. | 1 |
| 45-46. 47. | Тамырдаш сүзләр | 3 |
| 48 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Хикәя язу. “Кышкы уеннар”** | 1 |
| 49 | Кушымчалар | 1 |
| 50. | **Искәртмәле диктант. “ Кушымчалар”** | 1 |
| 51. | Үткәннәрне кабатлау | 1 |
| 52- 53 | Предметны белдерә торган сүзләр | 2 |
| 54 | **Искәртмәле диктант. “Предметны белдерә торган сүзләр”** | 1 |
| 55 | Исем һәм фамилияләрдә баш хәреф. | 1 |
| 56 | Ил, шәһәр, авыл, елга, күл исемнә-рендә баш хәреф | 1 |
| 57 | Ил, шәһәр, авыл, елга, күл исемнә-рендә баш хәреф | 1 |
| 58 | Хайван кушаматларында баш хәреф | 1 |
| 59 | **Контроль диктант. “Сүз”** | 1 |



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 14 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| **Сүзләрнең мәгънәләре 21 сәг** | | |
| 60 | Хаталар өстендә эш. Үткәннәрне кабатлау | 1 |
| 61-67 | Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр | 7 |
| 68 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Хикәя язу. “Ял көнендә “** | 1 |
| 69 | **Аңлатмалы диктант.” Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр”** | 1 |
| 70 | **Үткәннәрне кабатлау. Тест “Сүз”** | 1 |
| 71-75 | Билгене белдерә торган сүзләр | 5 |
| 76 | **Контроль диктант. “Билгене белдерә торган сүзләр”** | 1 |
| 77 | Хаталар өстендә эш. Билгене белдерә торган сүзләр | 1 |
| 78 | Билгене белдерә торган сүзләр | 1 |
| 79 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Рәсем буенча хикәя төзеп язу** | 1 |
| 80 | Хаталар өстендә эш. Үткәннәрне кабатлау | 1 |
| | **Җөмлә 7сәг** | |
| 81-83 | Җөмлә | 3 |
| 84-85 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. | 2 |
| 86 | Бәйләнешле сөйләм. | 1 |
| 87 | **Контроль диктант. “Җөмлә”** | 1 |
| **Сөйләм һәм текст** | | |
| 88 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Инша язу** | 1 |
| 89 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Рәсем буенча хикәя төзеп язу** | 1 |
| 90 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. План буенча изложение язу. “Зәһәр елан”** | 1 |
| 91 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Хат язу** | 1 |
| 92 | Бәйләнешле сөйләм. Телефоннан сөйләшү | 1 |



Документ создан в электронной форме. № 42 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 15 из 28. Страница создана: 23.05.2024 10:33
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| 93-94 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.  Изложение. Озын томшык** | 2 |
| **Кабатлау 8 сәг** | | |
| 95 | **Еллык контроль диктант** | 1 |
| 96 | Хаталар өстендә эш.Үткәннәрне кабатлау. | 1 |
| 97-98 | Үткәннәрне кабатлау. Алфавит | 2 |
| 99-100 | Үткәннәрне кабатлау. Сузык авазлар. | 2 |
| 101-102 | Үткәннәрне кабатлау. Тартык авазлар. | 1 |

## УКЫТУНЫҢ ӨЧЕНЧЕ ЕЛЫ

Программа **атнага 4  сәгать  исәбеннән 136 сәгатькә төзелде.**

**Предметның укыту планындагы урыны**

**1.Орфограмма. 1-2нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау (22 сәгать)**

Беренче һәм икенче сыйныфларда алган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне ныгыту, тирәнәйтү. Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тавышсыз хәрефләр. Парлы , парсыз һәм яңгырау ,саңгырау тартыклар. Калын һәм нечкә сузык авазлар. Е,я,ю хәрефләренең сүз башында ,сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү,шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу.ъ,ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку. Сүзгә фонетик анализ ясау

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

